Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы Советы

**КАРАР №LIV-6**

Балык Бистәсе штп. 2020 елның 5 августы

“Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә урнашкан муниципаль мөлкәтне һәм җир кишәрлекләрен файдаланган өчен аренда түләве һәм пеня буенча бурычларны (җирле бюджетка керү өлешендә) түләтүгә ышанычсыз дип тану һәм исәптән чыгару тәртибе турында”гы Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2015 елның 19 декабрендәге VI-7 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив хокукый актны законнарга туры китерү максатларында, “Россия Федерациясе Бюджет кодексының 47.2 маддәсенә үзгәрешләр кертү турында” 2020 елның 7 апрелендәге 114-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә урнашкан муниципаль мөлкәтне һәм җир кишәрлекләрен файдаланган өчен аренда түләве һәм пеня буенча бурычларны (җирле бюджетка керү өлешендә) түләтүгә ышанычсыз дип тану һәм исәптән чыгару тәртибе турында” гы Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2015 елның 19 декабрендәге VI-7 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

“Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә урнашкан муниципаль мөлкәтне һәм җир кишәрлекләрен файдаланган өчен аренда түләве һәм пеня буенча бурычларны (җирле бюджетка керү өлешендә) түләтүгә ышанычсыз дип тану һәм исәптән чыгару тәртибе”нең 1.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Мөлкәт өчен аренда түләве буенча бурыч, шулай ук аренда түләүләрен вакытында түләмәгән өчен (алга таба – бурыч) исәпләнгән пенялар түбәндәге очракларда түләтүгә ышанычсыз һәм исәптән чыгарылырга тиешле дип танылалар:

1) физик затның – бюджетка түләүләр түләүченең үлеме яисә аны Россия Федерациясе граждан процессуаль законнарында билгеләнгән тәртиптә вафат дип игълан итү;

2) "Бөлгенлек (банкротлык) турында" 2002 елның 26 октябрендәге 127 - ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә түләүчене – бурычлының мөлкәте җитәрлек булмавы аркасында бюджетка түләнмәгән түләүләр буенча бурыч өлешендә – индивидуаль эшкуарны банкрот дип тану;

2.1) “Бөлгенлек (банкротлык) турында” 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, индивидуаль эшкуар булмаган гражданны банкрот дип тану – күрсәтелгән Федераль закон нигезендә кредиторлар белән исәп-хисаплар тәмамланганнан соң бюджетка түләнмәгән түләүләр буенча бурычлар өлешендә;

3) бюджетка түләүләр түләүче оешманы мөлкәте җитмәгәнлектән һәм (яисә) аны әлеге оешманы гамәлгә куючылар (катнашучылар) тарафыннан Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән чикләрдә һәм тәртиптә каплау мөмкин булмаганга күрә бюджетка түләнмәгән түләүләр буенча бурыч өлешендә бетерү;

4) хөкем ителгәннәргә карата штраф яки суд тарафыннан карар кабул итү рәвешендә җәзага карата амнистия яки ярлыкау турындагы актларны куллану, аның нигезендә бюджет керемнәре администраторы бюджетка түләүләр буенча бурычларны түләтү мөмкинлеген югалта;

5) суд приставы-башкаручы тарафыннан башкарма производствоны тәмамлау турында түбәндәге очракларда карар чыгару һәм түләтүчегә “Башкарма производство турында" 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы Федераль законның 46 маддәсендәге 1 өлешенең 3 яки 4 пунктында каралган нигез буенча, әгәр бюджетка түләүләр буенча бурыч барлыкка килгән датадан соң биш елдан артык вакыт узган булса, башкарма документны кире кайтару турында карар чыгару:

бурыч күләме бөлгенлек турындагы эш буенча производство кузгату өчен бурычлының бөлгенлек (банкротлык) турында Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән таләпләр күләменнән артмый;

банкротлык турындагы эштә кулланыла торган процедураларны уздыруга суд чыгымнарын каплау өчен җитәрлек акча булмауга бәйле рәвештә банкротлык турындагы эш буенча эш туктатылу хакында суд тарафыннан гариза кире кайтарылу;

6) теркәүче орган карары буенча юридик затларның Бердәм дәүләт реестрыннан юридик затны төшереп калдыру һәм “Башкарма производство турында” 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы Федераль законның 46 маддәсендәге 1 өлешенең 3 яки 4 пунктында каралган нигез буенча башкарма документны түләтүчегә кире кайтаруга бәйле рәвештә башкару эшләрен тәмамлау турында суд приставы-башкаручы тарафыннан элек чыгарылган карарның булуы, – оешманың мөлкәте җитәрлек булмау һәм аны гамәлгә куючылар (катнашучылар) тарафыннан Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда түләү мөмкинлеге булмау сәбәпле бюджетка түләүләр буенча бурычлар өлешендә. “Юридик затларны һәм индивидуаль эшкуарларны дәүләт теркәвенә алу турында” 2001 елның 8 августындагы 129-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә юридик затны бердәм дәүләт реестрыннан төшереп калдыру турында теркәүче орган карарын гамәлдә түгел дип тану очрагында моңа кадәр әлеге пунктча нигезендә түләтүгә ышанычсыз

дип танылган бюджетка түләүләр буенча бурыч бюджет (бухгалтерия) исәбендә торгызылырга тиеш".

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы И.Р. Тажетдинов